АССОЦИАЦИЯ
«СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНЫХ
ОБРАЗОВАНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ
СОВЕТЫ»
АССОЦИАЦИЯСЕ

**РЕШЕНИЕ ПРЕЗИДИУМА** | **ПРЕЗИДИУМ КАРАРЫ**

от 12.03.2021 | № ПР-8-1

г. Казань

**«Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясенең XV съезды йомгаклары буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының уртак чаралар Планын гамәлгә ашыру буенча эшче төркемнәр төзү турында**

«Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе рәисе Ә.С. Гобәйдуллинның мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, «Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе Президиумы (алга таба - Совет) **карар итте**:

1. Совет рәисе Ә.С. Гобәйдуллинның мәгълүматын игътибарга алырга.

2. «Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясенең XV съезды йомгаклары буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының уртак чаралары Планын гамәлгә ашыру буенча эшче төркемнәр төзергә һәм кушымта нигезендә бүленешне расларга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Советның башкарма секретаре А.Г. Барышевка йөкләнә.

**Рәисе** **Ә.С.Гобәйдуллин**

000582

«Татарстан Республикасының
муниципаль берәмлекләре
Советы» Ассоциациясе Президиум
карары буенча
Кушымта
«12» 03 2021 ел
№ПР-8-1

«Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясенең XV съезды йомгаклары буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының уртак чаралары Планын гамәлгә ашыру буенча эшче төркемнәр

| № | Эшчәнлек юнәлеше | Төркем җитәкчесе / Төркем составы | Плана пунктлары |
|---|---|---|---|
| 1 | Стратегик планлаштыру, җитештерүләрне урнаштыру һәм территорияләрне комплексы үстерү, дәүләт программаларын, милли һәм инвестиция проектларын гамәлгә ашыру, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү, социаль-мәдәни эшчәнлек мәсьәләләре | Н. Г. Мәһдиев / Э. Н. Фәттахов | 1. Туган телләр һәм халык бердәмлеге елын үткәрүдә катнашу турында.<br>5. Халыкның эшлекле активлыгын стимуллаштыру, кече һәм урта бизнес субъектларына ярдәм итү турында.<br>6. Яңа коронавирус инфекциясенең таралуын булдырмауга юнәлтелгән чаралар турында.<br>7. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә федераль һәм республика программаларын гамәлгә ашыру буенча штаблар (проект офислары) төзү турында.<br>10. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать паркларының һәм мәйданчыкларының нәтиҗәлелеген арттыру турында.<br>11.Республиканың эре предприятиеләре тарафыннан муниципаль берәмлекләрдә филиаллар төзү турында. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 13. Фермерлар һәм шәхси эшмәкәрләр җитештергән продукцияне сату турында. |
| 2 | Җирле үзидарә үсеше (территорияләр белән идарә итүдә гражданнарның катнашуы, урыннарда депутатлар эше, референдумнар, җыеннар, үзара салым, грантлар, җирле үзидарә органнары структурасы, кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләләре) | С.А. Демидов / Г.Г. Хәкимов Ю.М. Некрасова | 2. Бөтенроссия халык санын алу турында.<br>3. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына депутатлар сайлау турында.<br>4. Алга таба җирле үзидарә органнарының халык белән диалогын ныгыту турында.<br>8. Муниципалитетлар эшендә иң яхшы тәҗрибәләрне гомумиләштерү һәм алар турында муниципаль берләшмәләргә мәгълүмат бирү турында.<br>9. Җирлек дәрәҗәсендәге муниципаль берәмлекләр башлыкларының югары алмашуы турында.<br>17. Җирле үзидарә органнарының контроль-күзәтчелек органнары белән хезмәттәшлеге нәтиҗәлелеген арттыру турында.<br>18. Җирле үзидарә органнары структурасын камилләштерү турында.<br>24. Авыл җирлекләре һәм поселокларның башкарма комитетлары җитәкчеләре урынбасарларының (сәркәтипләренең) муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләрен камилләштерү турында. |
| 3 | Территориаль планлаштыру мәсьәләләре (төзелеш, капиталь ремонт, генераль планнар, җирдән файдалану кагыйдәләре, санитар саклау зоналары, муниципаль милек объектлары буенча мәгълүматлар базасын формалаштыру һ. б.) | Т. Д. Ногманов / В.С. Чершинцев | 12. Авылда яшь гаиләләргә ярдәм итү өчен шартлар тудыру турында.<br>15. Инвентаризацияне тәмамлау һәм гидротехник корылмаларны алга таба эксплуатацияләү турында.<br>16. Территориаль планлаштыру документларын федераль закон таләпләренә туры китерү турында.<br>19. Муниципалитетларның «Авыл территорияләрен |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | комплексы үстерү» дәүләт программасы чараларында катнашу эшен активлаштыру турында.<br>20. «Авыл территорияләрендә транспорт инфраструктурасын үстерү» ведомство проектында «Авыл территорияләрен комплексы үстерү» дәүләт программасының катнашуы турында.<br>21. «Авыл территорияләрен комплексы үстерү» дәүләт программасының «Авыл территорияләренең заманча йөзе» ведомство максатчан программасында катнашу турында. |
| 4 | Территорияләрне инфраструктура ягыннан үстерү (су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, яктырту, юлларны, ГТСларны карап тоту, торак пунктларны, ишегалды территорияләрен төзекләндерү; Күмү урыннарын карап тоту; җәмәгать киңлекләрен, ККК, "Безнең ишегалды" программасы һ. б.) | Р.Н. Минниханов / В.М. Козлов Н.В. Әйдова | 14. Иҗтимагый киңлекләрне үстерү турында.<br>22. Сәүдә предприятиеләре һәм муниципаль оешмалар өчен коммуналь калдыкларны туплауның югары нормативлары турында.<br>23. Кышкы чорда авыл җирлекләрендә юл челтәрен карап тоту турында.<br>25. Халыкны су белән тәэмин итү объектларын төзү һәм реконструкцияләү турында.<br>26. Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча вәкаләтләрне үтәү буенча муниципаль берәмлекләрне тиешле дәрәҗәдә финансламау турында. |